РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:
Kukmor.Kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24 сентябрь 2019 ел № 82

Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре
муниципаль берәмлек милкендә булган муниципаль
милекне сату буенча конкурс шартларын эшләү һәм
раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту һәм
конкурс җиңүчесе тарафыннан мондый шартларның
үтәлешен раслау Тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яки муниципаль милекне сату буенча конкурс үткәрү нигезләмәсен раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 584 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә карар бирәм:

1. Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлек милкендә булган муниципаль милекне сату буенча конкурс шартларын эшләү һәм раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту һәм конкурс җиңүчесе тарафыннан мондый шартларның үтәлешен раслау Тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Хәйруллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Р.Ф. Нотфуллин

Кукмара муниципаль
районы Кукмара шәһәре
Башкарма комитетының
24.09.2019 елгы №82
карарына кушымта

Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлек милкендә булган муниципаль милекне сату буенча конкурс шартларын эшләү һәм раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту һәм конкурс җиңүчесе тарафыннан мондый шартларның үтәлешен раслау Тәртибе

**Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Тәртип «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яки муниципаль милекне сату буенча конкурс үткәрү нигезләмәсен раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 584 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлек милкендә булган муниципаль милекне (алга таба шулай ук – муниципаль милек, объект) аны конкурста сату юлы белән хосусыйлаштырганда конкурс шартларын эшләү һәм раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту һәм конкурс җиңүчесе тарафыннан мондый шартларның үтәлешен раслау Тәртибен билгели.

2. Конкурс шартларын эшләү һәм раслау тәртибе

2.1. Конкурста муниципаль милекне сату буенча сатучы булып Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Комитет) тора.

2.2. Конкурс шартларын эшләү Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла (алга таба – Комитет).

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (алга таба – мәдәни мирас объекты) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) сатылган очракта, мәдәни мирас объектларын сату буенча конкурс шартлары мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелергә тиеш.

2.3. Шартларны эшләү максатыннан Комитет конкурс шартлары буенча тәкъдимнәр бирү турында сорату җибәрә (алга таба – сорату):
- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына;
- Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына;
- Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау башкарма органына.

2.4. Конкурс шартлары буенча тәкъдимнәр комитетка сорату алу вакытыннан алып унбиш календарь көннән дә артмаган вакыт эчендә тапшырыла.

2.5. Конкурс шартлары түбәндәгеләрне карарга мөмкин
- эш урыннарының билгеле бер санын саклап калу;
- хезмәткәрләрне яңадан әзерләү һәм (яки) квалификациясен күтәрү;
- унитар предприятие эшчәнлегенең профилен үзгәртүне яки халыкка социаль-мәдәни, коммуналь-көнкүреш яки транспорт хезмәте күрсәтүнең аерым объектларының билгеләнешен яки аларны куллануны туктатуны чикләү;
- мәдәни мирас объектларына, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларына карата реставрация, ремонт һәм башка эшләр башкару.

Бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объекты сатылган очракта, конкурс шартлары, сакчылык йөкләмәсе нигезендә, мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкаруны күздә тотарга тиеш.

Конкурс шартларының икътисадый нигезе, аларны үтәү сроклары, конкурста җиңүче тарафыннан мондый шартларны үтәүне раслау тәртибе булырга тиеш. Конкурс шартлары үзгәртелми. Конкурс шартлары исемлеге тулы була.

2.6. Конкурсның шартлары, аларны үтәү сроклары, конкурста җиңүче тарафыннан мондый шартларны үтәүне раслау тәртибе Комитет җитәкчесе карары белән раслана.

2.7. Конкурс шартлары аны үткәрү турында мәгълүмати хәбәрдә урнаштырылырга тиеш.

3. Конкурс шартларын үтәүне контрольдә тоту тәртибе

3.1. Конкурс шартлары үтәлеше конкурс җиңүчесе белән төзелгән муниципаль милекне сату-алу килешүе нигезендә Комитет тарафыннан контрольдә тотыла.

3.2. Конкурс шартларын үтәүне нәтиҗәле контрольдә тотуны тәэмин итү өчен Комитет түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

- конкурс нәтиҗәләре буенча төзелгән муниципаль милекне сату-алу килешүләрен исәпкә алып барырга;

- конкурста җиңүчеләрнең муниципаль милекне сату-алу килешүләрендә билгеләнгән йөкләмәләрен һәм аларның үтәлешен контрольдә тотуны исәпкә алып барырга;

- конкурс җиңүчеләреннән конкурс шартларының үтәлешен раслаучы хисап документларын кабул итәргә;

- конкурс җиңүчеләре тарафыннан конкурс шартларының үтәлешен раслап тапшырыла торган документларны тикшерүне үткәрергә, шулай ук тикшерелә торган объектлар урнашкан урында конкурс шартларының чынлыкта үтәлешен тикшерергә;

- Россия Федерациясе законнары һәм муниципаль милекне сату-алу килешүендә закон бозуларны бетерүгә һәм конкурс шартларын үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә.

3.3. Конкурста җиңүченең хисап документларын тапшыру вакыты һәм формасы конкурс шартлары һәм, документларның кварталга бер тапкырдан артык тапшырылмавын исәпкә алып, муниципаль милекне сату-алу килешүе белән билгеләнә

3.4. Конкурс шартларын үтәүне контрольдә тоту максатыннан, Комитет тарафыннан конкурс шартларын үтәүне контрольдә тоту комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Конкурс шартларының үтәлеше турында җыелма (йомгаклау) хисап алынганнан соң ике ай эчендә Комиссия конкурс җиңүчесе тарафыннан тәкъдим ителгән хисап нигезендә конкурс шартларының факттагы үтәлешен тикшерә.

3.5. Комиссия конкурс җиңүчесе белән төзелгән муниципаль милекне сату-алу килешүе нигезендә конкурста җиңүчедән кергән конкурс шартларын үтәү белән бәйле документлар анализын үз эченә алган конкурс шартларын үтәүне һәм тикшерелә торган объектлар урнашкан урында конкурс шартларының чынлыкта үтәлешен тикшерә.

3.6. Комиссия 7 кешедән төзелә.

Комиссия составына түбәндәге вәкилләр кертелә:

- Комитет вәкиле;

- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты вәкиле (килешү буенча);

- Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы вәкиле;

- мәдәни мирас объекты сатылган очракта, мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма орган вәкиле (килешү буенча);

3.7. Комиссия үз эшен оештыру тәртибен мөстәкыйль билгели. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

3.8. Комиссия утырышы комиссия әгъзалары имза салган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Карарлар комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4. Конкурс җиңүчесе тарафыннан конкурс шартларын үтәүне раслау тәртибе

4.1. Конкурс шартлары үтәлү вакыты узганнан соң ун эш көне эчендә җиңүче комиссиягә конкурс шартларының үтәлеше турында, барлык кирәкле документларны да кушып, җыелма (йомгаклау) хисап җибәрә.

4.2. Конкурс шартлары үтәлеше турындагы җыелма (йомгаклау) хисапны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия конкурс җиңүчесе тарафыннан конкурс шартларының үтәлүе турында акт төзи. Конкурс шартларын үтәү турында Комиссия актында мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр чагылдырылырга тиеш:

- актның номеры, төзү вакыты, урыны;
- Комиссия составы;
- җәлеп ителгән эксперт һәм консультантлар составы;
- Конкурс шартлары;
- әлеге шартларның үтәлешен раслаучы документлар исемлеге;
- конкурс шартлары үтәлешен җиңүче дип тану мәсьәләсе буенча экспертларның (билгеләнгән очракта) бәяләмәләре, комиссия тәкъдимнәре һәм нәтиҗәләре;
- җиңүченең Ф.И.О., (атамасы).

Әлеге акт җыелма (йомгаклау) хисапны тикшерү эшендә катнашкан комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.3. Комиссиянең Конкурс шартларын үтәү турында Акты Комитет тарафыннан раслана.

4.4. Комиссия имзалаган актны Комитет раслаганнан соң, конкурс шартларын үтәү буенча конкурста җиңүченең йөкләмәләре тулы күләмдә үтәлгән булып санала.

4.5. Конкурста җиңүче тарафыннан аның шартларын, шулай ук аларны тиешенчә үтәмәгән очракта, шул исәптән мондый шартларның үтәлү күләмен һәм аларны үтәүнең арадаш яки ахыргы срокларын бозган очракта, муниципаль мөлкәтне сатып алу-сату килешүе якларның килешүе буенча яки суд тәртибендә сатып алучыдан бер үк вакытта неустойка түләттерү белән өзелә.